КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 май г.Казань № 655

Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турындагы нигезләмәне (алга таба – Нигезләмәне) расларга.

2. 2024 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру әлеге Нигезләмәгә таянып башкарыла дип билгеләргә.

3. Республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасы бюджеты һәм бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары акчасы белән бүтән баш эш итүчеләргә түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы дәүләт программаларын үтәү өчен җаваплы территориаль органнарына (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт программаларының җаваплы башкаручылары) – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

2023 елның 15 июленә кадәр Нигезләмәгә таянып эшләнгән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау, Татарстан Республикасы дәүләт программаларына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүне тәэмин итүне;

Татарстан Республикасы дәүләт программалары расланган яки аларга үзгәрешләр кертелгән датадан 14 календарь көн эчендә аларның паспортларын үзләренең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында һәм Россия Федерациясе дәүләт программалары порталында (www.programs.gov.ru) урнаштыруны тәэмин итүне;

2024 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан

Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе нигезендә 2023 елга Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру турында еллык хисаплар тапшыруны тәэмин итүне.

4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына:

2023 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы дәүләт программаларының җаваплы башкаручылары белән үзара хезмәттәшлек итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге үз көчен югалткан дип тану турында һәм, Татарстан Республикасы дәүләт программалары кураторларын, җаваплы башкаручыларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру чорларын күрсәтеп, 2024 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә ашырылачак Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә;

2024 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт программалары нәтиҗәлелеген бәяләүне тәэмин итәргә.

5. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2024 елның 1 гыйнварыннан, Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлегенә үзгәрешләр кертергә кирәк булганда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының тиешле карары проекты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы турында һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү хакында җыелма еллык докладны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе карарларын үтәү йөзеннән, чираттагы финанс елының 15 июненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт программаларының җаваплы башкаручылары белән үзара хезмәттәшлектә эшләнелә;

2023 елның 1 августына кадәр расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары чараларын гамәлгә ашыру максатларында төзелгән дәүләт контрактларында (шартнамәләрдә, контрактларда, килешүләрдә) бюджетлар чыгымнары классификациясе кодлары һәм (яки) Татарстан Республикасының әлеге дәүләт

программаларына сылтамалар күрсәтелгән очракта, мондый кодларны һәм (яки) сылтамаларны үзгәртү максатларында әлеге дәүләт контрактларына (шартнамәләргә, контрактларга, килешүләргә) үзгәрешләр кертү таләп ителми.

6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, 2026 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Нигезләмәнең нормаларын исәпкә алып, муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен эшләүне һәм раслауны тәкъдим итәргә.

7. 2025 елның 1 гыйнварыннан кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары үз көчен югалткан дип танырга.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин